Республика Татарстан
СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДЕБӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422071, Татарстан Республикасы,
Килдебәк авылы, Кооператив урамы, 20айорт
тел. 45-5-50

e-mail: Kilb.Sab@tatar.ru

20 сентябрь 2019 ел № 17

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Килдебәк авыл җирлеге Советы тарафыннан
2009 нчы елның 21 нче декабрендә кабул ителгән
18 нче номерлы " Регламентны раслау турында »
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының 2019 нчы елның 10 нчы сентябрендә кабул ителгән 02-01-20-19 нчы номерлы протесты нигезендә, Килдебәк авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы тарафыннан 2009 нчы елның 21 нче декабрендә кабул ителгән 18 нче номерлы регламентнын 6 бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 34.1 статья белән тулыландырырга:

1.Килдебәк авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук, Килдебәк авыл җирлеге Уставы һәм закон белән вәкаләтле башка вазыйфаи затлар советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Килдебәк авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Башкарма комитет хезмәткәрләре Совет тарафыннан алар карамагына караган мәсьәләләрне караганда ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр бу тәкъдим депутатларның гомуми санынннан абсолют күпчелеге тарафыннан кабул ителсә, Совет утырышында җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Таләп кимендә өч көннән дә соңга калмыйча утырышка кадәр Совет рәисе тарафыннан, утырышны уздыру вакытын, урынын күрсәтеп, чакырылган вазыйфаи затның белешмәләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаи затның Совет утырышына чакыртыла торган мәсьәләсенә җиткерелә.

5. Совет рәисе утырыш ачылыр алдыннан утырышта катнашучы Совет депутатлары булмаган затлар турында хәбәр итә.

6. Утырышта катнашучылар һәм чакырылган затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел (чыгыш ясарга, гариза ясарга, хуплау яисә канәгатьсезлек белдерергә).

7. Совет карары буенча чакырылган затларга регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.

8.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Заһидуллин